**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге составына керүче Комсомолец авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

33 ноябрь, 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2020 елда яшәү урыны буенча Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Комсомолец бистәсендә юлларны ремонтлау;
2) Комсомолец бистәсендә вак ташлы юл төзү;
3) балалар мәйданчыклары өчен урам спорт тренажерлары һәм кече архитектура формалары сатып алу;
4) Комсомолец бистәсендә тротуарлар төзү;
5) Комсомолец бистәсендә чишмәне төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **673** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **344** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **320** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **24** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныпга.

2. «2020 елда яшәү урыны буенча Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Комсомолец бистәсендә юлларны ремонтлау;

2) Комсомолец бистәсендә вак ташлы юл төзү;

3) балалар мәйданчыклары өчен урам спорт тренажерлары һәм кече архитектура формалары сатып алу;

4) Комсомолец бистәсендә тротуарлар төзү;

5) Комсомолец бистәсендә чишмәне төзекләндерү

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныпга.

3. Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комсомолец авыл җирлеге Башлыгы О.В. Сурова